| | | |
|---|---|---|
| **СОВЕТ ЮШАДИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНЗЕЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЮШАДЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ** |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

# КАРАР

## Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Юшады авыл җирлеге составына кергән Югары Юшады торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**2019 ел, 20 ноябрь** **№ 3**

2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы №131-ФЗ нең 25.1, 56 маддәләре, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы №45-ЗРТ Законының 35 маддәсе нигезендә 2019 елның 17 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар түбәндәге мәсьәлә буенча җыен беркетмәсе төзелде: “2020 елда Минзәлә муниципаль районы Юшады авыл җирлегенең Югары Юшады торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән (*көндезге формада укучы студентлардан, БВС ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында, хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннарыннан, 1 һәм 2 нче төркем инвалидлардан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән, күп балалы гаиләләрдән тыш*) 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган чараларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә Сез ризамы?”

- Зират коймаларын урнаштыру (материал сатып алу, хезмәтләр өчен килешү буенча түләү).
- Зират капкаларын урнаштыру.
- торак пунктның зират территориясендә инвентарь кую өчен техник бина төзелеше (материал сатып алу, хезмәтләр өчен килешү буенча түләү).
- Инвентарь һәм зират өчен җиһаз сатып алу.
- Зират өчен контейнерлар сатып алу.
- Кышкы чорда юлларны грейдерлау.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 98 гражданнар җыенында катнашучы кертелгән, тавыш бирүдә катнашучы гражданнар җыенында катнашучылар саны 53 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленде:
“Әйе” позициясе өчен 53 гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде;
“Юк” позициясе өчен 0 җыенда катнашучы тавыш бирде.

Югарыда бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар чыгарды:

1.Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Юшады авыл җирлегенең Югары Юшады торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен – гамәлдә дип танырга.
2.2020 елда Минзәлә муниципаль районы Кадрәк авыл җирлегенең Кадрәк торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән (*көндезге формада укучы студентлардан, БВС ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында, хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннарыннан, 1 һәм 2 нче төркем инвалидлардан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән, күп балалы гаиләләрдән тыш*) 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган чараларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә Сез ризамы?” мәсьәләсе буенча карарны танырга һәм алынган чараларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Зират коймаларын урнаштыру (материал сатып алу, хезмәтләр өчен килешү буенча түләү).
- Зират капкаларын урнаштыру.
- торак пунктның зират территориясендә инвентарь кую өчен техник бина төзелеше (материал сатып алу, хезмәтләр өчен килешү буенча түләү).
- Инвентарь һәм зират өчен җиһаз сатып алу.
- Зират өчен контейнерлар сатып алу.
- Кышкы чорда юлларны грейдерлау.

2. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Юшады авыл җирлеге Советының мәгълүмати стендларында, Минзәлә мунициπаль районы сайтында: http://menzelinsk.tatarstan.ru/ Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы һәм http://pravo.tatarstan Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматенең рәсми порталы составында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.
3. Гамәлдәге карарны Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Юшады авыл җирлегенә җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: М.М.Боков.__________________ (имза) ________________(тулысынча имза)

Юшады авыл җирлеге Башлыгы
Совет рәисе ______________М.М.Боков. (имза) (тулысынча имза)